ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

_____24.11.2025____________ № _848_____

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының физкультура-савыктыру һәм спорт чараларының календарь планына кертелгән физкультура-савыктыру, спорт һәм укыту-тренировка чараларын уздыру чыгымнары нормаларын раслау турында**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының физкультура-савыктыру һәм спорт чараларының календарь планына кертелгән физкультура-савыктыру, спорт һәм укыту-күнегүләр (тренировка) чараларын уздыруга чыгымнар нормаларын тәртипкә китерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының физкультура-савыктыру һәм спорт чараларының календарь планына кертелгән физкультура-савыктыру, спорт һәм күнегүләр чараларын уздыруга чыгымнар нормаларын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 18 мартындагы 160 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»  2025 елның 09 апрелендәге 208 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Түбәндәгеләрне расларга:

- физкультура-савыктыру, спорт һәм күнегүләр үткәргәндә спортчыларны, тренерларны, машина йөртүчеләрне һәм белгечләрне тәүлеклеклек белән тәэмин итү чыгымнары нормаларын (1 нче кушымта);
- физкультура-савыктыру, спорт һәм укыту-күнегү (тренировка) чараларында спортчыларны, тренерларны, машина йөртүчеләрне һәм башка катнашучыларны яшәп тору урыны белән тәэмин итү чыгымнары нормаларын (2 нче кушымта);
- спорт чараларына хезмәт күрсәткән өчен спорт судьяларына түләү чыгымнары нормаларын (3 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының рәсми сайтында https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Сабирҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф.Хәкимуллин

Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль
районы Башкарма
комитетының 24.11.2025
848нче номерлы
карарына 1 нче кушымта

**Физкультура-савыктыру, спорт һәм тренировка чаралары үткәргәндә спортчыларны, тренерларны, машина йөртүчеләрне һәм белгечләрне тәүлеклеклек белән тәэмин итү чыгымнары нормалары**

| № т/б | Спорт чаралары исеме | Бер кешегә көненә чыгымнар нормасы, сум |
|---|---|---|
| 1. | Массакүләм физкультура-спорт ярышлары һәм чаралар | 365 кадәр |
| 2. | Татарстан Республикасы чемпионатлары, беренчелекләре, кубоклары һәм аларга тренировка чаралары (спартакиадалар, универсиадалар) | 425 кадәр |
| 3. | Бөтенроссия ярышлары һәм аларга тренировка чаралары үткәрү | 730 кадәр |
| 4. | Олимпия булмаган һәм паралимпия булмаган спорт төрләре буенча Халыкара ярышлар һәм аларга карата тренировка чаралары | 785 кадәр |
| 5. | Олимпия һәм паралимпия спорт төрләре буенча Халыкара ярышлар һәм аларга карата тренировка чаралары | 850 кадәр |
| 6. | Биектау муниципаль районы территориясендә | 200 кадәр |

Искәрмә:

1. Авырлыгы 90 кг нан артык һәм/яки буе 190 см дан биегрәк булган спортчыларга аерым очракларында әлеге кушымтада билгеләнгән нормаларның каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә 50 процентка кадәр күтәрелергә мөмкин.

2. Акчасыз исәп-хисап буенча спорт чараларын уздыру урыннарында тәүлеклекләр белән тәэмин итү мөмкинлекләре булмаганда, спорт чараларында катнашучыларга әлеге кушымтада китерелгән чыгымнар нормалары чикләрендә акчалата бирү рөхсәт ителә.

3. Татарстан Республикасы территориясендә уздырыла торган Бөтенроссия ярышларында катнашучы спортчылар республика ярышлары чыгымнары нормалары чикләрендә тәүлеклеклек белән тәэмин ителәләр.

4. Спорт чараларын үткәргәндә барлык категория спорт судьялары тәүлеклеклек белән тәэмин ителми.

5. Чараларны үткәрүче оешмалар бюджеттан тыш, иганәчелек акчалары, шулай ук гариза кертемнәре исәбеннән барлык категория судьяларга, спортчыларга, тренерларга, машина йөртүчеләргә һәм белгечләргә тәүлеклек компенсация түләүләрен башкарырга хокуклы.

Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль
районы Башкарма
комитетының 24.11.2025
848нче номерлы
карарына 2 нче кушымта

**Физкультура-савыктыру, спорт һәм укыту-тренировка чараларында спортчыларны, тренерларны, машина йөртүчеләрне һәм башка катнашучыларны яшәп тору урыны белән тәэмин итү чыгымнары нормалары**

| № т/б | Яшәп тору өчен торак пунктларның категорияләре исеме | Бер кеше-көн бәясе, сум |
|---|---|---|
| 1. | Мәскәү, Санкт-Петербург, Сочи шәһәрләре | 1120 кадәр |
| 2. | Россия Федерациясе субъектларының административ үзәкләре; Ерак Төньяк территорияләренә кертелгән шәһәрләр, торак пунктлар | 1120 кадәр |
| 3. | Россия Федерациясе территориясендәге башка шәһәрләр һәм торак пунктлар | 850 кадәр |

Искәрмә:

1. Спортчыларны, тренерларны һәм физкультура-савыктыру, спорт һәм укыту-тренировка (тренировка) чараларында катнашучыларны акчасыз исәп-хисап буенча яшәү белән тәэмин итү мөмкинлекләре булмаганда, әлеге кушымтада китерелгән чыгымнар нормалары чикләрендә акчалата бирү рөхсәт ителә.

2. Ярышларда чыгым нормаларында күрсәтелгән суммага яшәү мөмкин булмаган очракта, каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә сумма түләгенә 1300 сумга кадәр күтәрелергә мөмкин.

Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль
районы Башкарма
комитетының 24.11.2025
848нче номерлы
карарына 3 нче кушымта

**Спорт чараларына хезмәт күрсәткән өчен спорт судьяларына түләү чыгымнары нормалары**

| № т/б | Судья вазыйфаларының аталышы | Судьялар категорияләрен исәпкә алып, түләүләр күләмнәре, сум | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | МК,ВК | 1К | 2К | 3К/Ю/С | категориясез |
| 1. | Баш судья | 745 | 630 | - | - | - |
| 2. | Баш судья - секретарь | 745 | 630 | - | - | - |
| 3. | Баш судья, баш секретарь урынбасары | 685 | 570 | 455 | - | - |
| 4. | Судьялар | 640 | 510 | 435 | 400 | 340 |
| Спортның командалы уен төрләре | | | | | | |
| 5. | Уенның баш судьясы | 435 | 400 | - | - | - |
| 6. | Уенның баш судьясы ярдәмчесе | 365 | 340 | - | - | - |
| 7. | Инспектор (техник делегат, комиссар) | 435 | - | - | - | - |
| 8. | Судьялар (бригада составында) | 330 | 310 | 285 | 260 | 230 |

Шартлы билгеләр:
МК – халыкара категорияле спорт судьясы;
ВК – Бөтенроссия категорияле спорт судьясы;
1К – беренче категорияле спорт судьясы;
2К – икенче категорияле спорт судьясы;
3К – өченче категорияле спорт судьясы;
Ю/С –яшь спорт судьясы.

Искәрмә:

1. Түләүләр күләме ярышларның бер көненә хезмәт күрсәтү өчен каралган, бер уенга хезмәт күрсәтү өчен түләүләр башкарыла торган командалы уен спорт төрләреннән тыш (футбол, алкалы хоккей, баскетбол, волейбол, су полосы, гандбол, туплы хоккей, чирәмдәге хоккей, бейсбол, регби һ. б.).

2. Ярышларның әзерлек һәм йомгаклау этабында баш судьяга, баш судья-секретарьга, баш судья урынбасарына һәм баш судья –секретарь урынбасарына яшәп тору, эш өчен түләү өстәмә рәвештә 2 көнгә арта.

3. Судьялар коллегияләренең (бригадаларының) сан составы спорт төрләре буенча ярышлар уздыру турында расланган Кагыйдәләр нигезендә билгеләнә.

4. Халыкара, бөтенроссия ярышлары, Татарстан Республикасы чемпионатлары һәм кубоклары уеннарын оештыруны һәм уздыруны контрольдә тоту өчен уеннарның баш судьялары өчен каралган күләмнәрдә түләүле инспекторлар яисә техник делегатлар билгеләп куелырга мөмкин.